# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Кук-Тау авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 14 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Кук-Тау авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Кук-Тау авыл җирлеге территориясендә I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) гомуми автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге файдалану:
-Кук-Тау торак пунктында Беларус-82,1 тракторын тоту (водитель хезмәтләренә түләү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
-авыл эчендәге юлны ремонтлау (асфальт белән капланган юлны чокырлы урыннарын ремонтлау, сатып алу, ташу, асфальт валчыклар салу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) Кук-Тау торак пунктының Яшел урамына;
2) урам яктырту җайланмасы:
- Кук-Тау торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
3) Кук-Тау торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү:
- зират территориясенә койма тоту өчен материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
4) Кук-Тау торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын кранын урнаштыру);
3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р.Нуртдинов